ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:
«$5^1$) энергетика;»;

2) 9 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:
«$4^1$. Генераль планга җирлек яисә шәһәр округы составына керүче торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) турындагы белешмәләр кушымта итеп бирелергә, аларда торак пунктлар чикләре урнашкан җиренең график тасвирламасы, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында шушы чикләрнең характерлы нокталарының координаталары исемлеге булырга тиеш.»;

3) 10 статьяда:
а) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9. Генераль планны әзерләгәндә мәҗбүри рәвештә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ һәм 28 статьялары нигезендә җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә.»;
б) 13 өлештә «гавами тыңлаулар» сүзләрен «җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 12 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 15 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба – комиссия) җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектны әзерләү максатларында төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора. Комиссия Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелгәндә аларны оештыручы булырга мөмкин.»;

6) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктында «Россия Федерациясенең башка субъектлары белән килештереп, Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясенең ике һәм аннан артыграк субъектлары» сүзләрен «Россия Федерациясенең башка субъекты (башка субъектлары) белән килештереп, Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясенең башка субъекты (башка субъектлары)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә «нормативларына,» сүзеннән соң «юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларына, юл хәрәкәтен оештыру нәтиҗәлелеген тәэмин итү буенча «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 11 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 6 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 6 пунктының «б» пунктчасы 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 29-ТРЗ